**СОВЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03 сентябрь 2020ел. Иске-Тәрбит авылы № 14

Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Бурычларны, штрафларны һәм процентларны түләтүгә өметсез дип табылган недоимканы, штрафларны һәм процентларны исәпләү тәртибен раслау турында» 2010 елның 19 августындагы ЯК-7-8/393 номерлы боерыгының 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны (алга таба - бурыч) түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

- җир салымы һәм вафат булган физик затлар мөлкәтенә салым буенча, мираска гариза бирелмәгән очракта, өч елдан артык бурыч барлыкка килгән дата белән;
- балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче, ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балигъ булмаган гражданнар - җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча.

2.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Иске-Тәрбит авыл җирлеге
Башлыгы

В.Г.Тимофеев